ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИДЕЛ БУЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

2020 елның 24 гыйнвары №91-1

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Идел Буе авыл җирлеге Советының 2015 елның
12 октябрендәге 2-2 номерлы «Җир салымы турында»
карарына үзгәрешләр кертү турында
(26.05.2017 ел, №33-1, 02.07.2019 ел,
№ 76-2 үзгәрешләр белән,
2009 ел, 08 октябрь, 82-5 нче карары)

Россия Федерациясе Салым кодексының 394 статьясы, «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына салымнар һәм җыемнар турында» Федераль законның 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 15 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 23 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Идел Буе авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Идел Буе авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 октябрендәге 2-2 номерлы «Җир салымы турында» карарына (26.05.2017 ел, №33-1, 19.11.2019 ел,№ 86-1 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә :

1.1. 2 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3 %.».

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә закон көченә керә.

3. Әлеге карарны Идел Буе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru), һәм хокукый мәгълүмат сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Идел буе авыл җирлеге башлыгы: С.Г.Спирин

СОВЕТ ПРИВОЛЖСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ